ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУСЛЮМОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӨСЛИМ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

_29.06.2021__ М ө с л и м № _263_

**«Дүрт һәм аннан да күбрәк балалары булган күп балалы гаиләләрдәге балалар өчен түләүсез туклануны оештыру турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 елның 22 мартындагы 124 номерлы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү турында**

Техник хатага бәйле рәвештә, Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 22 мартындагы 124 номерлы карары белән расланган Дүрт һәм аннан да күбрәк балалары булган күп балалы гаиләләрдәге балалар өчен түләүсез туклануны оештыру турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.1. Әлеге нигезләмә гомуми белем бирү учреждениеләренең 5-11 сыйныфларында белем алучы дүрт һәм аннан да күбрәк балалары булган гаиләләргә адреслы, максатчан социаль ярдәм күрсәтү максатларында эшләнде һәм аларны бер тапкыр бушлай туклану белән тәэмин итү шартларын билгели».

1.2 пунктта «төп критерийлар» сүзләрен «критерий» сүзе белән алмаштырырга.

1.2. 2.1 пунктның икенче җөмләсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Бирелгән документлар нигезендә гомуми белем бирү учреждениесе директоры боерыгы рәсмиләштерелә».

1.4. 2.10 пунктта «мәктәп» сүзен «учреждение» сүзенә алмаштырырга.

1.5. 2.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.3. Мөрәҗәгать итүчеләрнең гаризалары елга ике тапкыр: сентябрьдә 30 числога кадәр, гыйнварда 30 числога кадәр карала».

1.6. 2.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.5.Учреждение укучыларның туклануын оештыру һәм аның сыйфаты өчен җаваплы».

1.7. 2.10, 2.12 пунктларны төшереп калдырырга.

2. Карарга бирелгән кушымтадан «аз тәэмин ителгән» сүзен һәм «_______нән _________ кадәр гамәлдә булган ___ номерлы таныклык» җөмләсен төшереп калдырырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (https://pravo.tatarstan.ru/) һәм Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы сайтында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең социаль-мәдәни үсеш буенча урынбасары М. Р. Бәдретдиновага йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Р.Т. Демидов**